**СОВЕТ**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 сентября 2024 Күләгәш авылы № 50-1

2024 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2024 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның кушымта итеп бирелгән Фараз планын (программасын) расларга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына,кушымта нигезендә, муниципаль мөлкәтне гамәлгә ашыру гамәлләрен башкарырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары урнашкан урында махсус бирелгән мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге порталы составында Күләгәш авыл җирлегенең рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе
Авыл җирлеге башлыгы В.А.Николаев

Совет Кулегашского сельского поселения Күләгәш авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының 12.09.2024 елның 50-1 номерлы карары белән расланды

## 2024 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегe муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

### I бүлек. 2024 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары

2024 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кулегаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә эшләнде.

Муниципаль мөлкәт белән идарә итү системасының базар икътисады шартларында төзелә торган өлеше буларак 2024 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге (алга таба – авыл җирлеге)җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә муниципаль милек структурасын оптимальләштерү тора.

2024 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып:

- омуниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан авыл җирлеге бюджетына салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- авыл җирлеге бюджетының керем өлешен арттыру;
- мөлкәтне тотуга авыл җирлеге бюджетыннан чыгымнарны киметү.

2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге мөлкәтен хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә авыл җирлеге икътисадында структур үзгәрешләр көтелми. 16:01:010502:56 кадастр номерлы 1,8 кв. м мәйданлы су башнясыннан файдалану зарурлыгы булмау сәбәпле, керем өлешен тулыландыру өчен хосусыйлаштыру планын расларга.

Хосусыйлаштыру 2024 елда планлаштырыла торган мөлкәт исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба да оптимальләштерүне исәпкә алып өстәлә.

## 2 бүлек. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәте

| № т/с | Объект | Чыгарылыш елы | Адрес | Хосусыйлаштыру ысулы | Хосусыйлаштыру вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Су башнясы, мәйданы 1,8 кв. м., кадастр № 16:01:010502: 56 | 1989 | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әгерже муниципаль районы, Күләгәш авыл жирлеге, Күләгәш авылы, Урман урамы, 13 нче бина | Ачык аукцион | 2024 ел | Кулланылмый |